Сафия Ариф кызы Шехмаметьева Ельник районы Чvриле - Чурино авылындагы матур йортларнын берсендә яши.
Нинди тиз гомер vткән, кvпме сулар аккан... Белем-тәрбия биреп vстергән балалар аяк остенә нык басканнар, сагынып оныклар йореп тора, онықчык-лар шатландырып топырдап vсә. Бер карашка, ял итәргә дә итәргә... Юк, туксан яшен тутырган Сафия Ариф кызы Шехмаметьева, алдагы елларда тосле, кунакларны милли ашларын пешереп котә. Дус кызлары еш килә ана; тормыш яналыклары белән уртаклашалар, хәтерләрен янартып гомерләренен сикәлтәле юлларын барлыйлар. Үткәннәрне искә алганда йорәкләре чемердәп китә апаларнын. Кvпме авырлык кvргән алар яшь чакларында - ихтыярсыз кvз яшьләре ага.       Бу буын кешеләренен балачагы белән яшьлекләрен сугыш «урлый». Язма героем белән дә шулай була. Чvриледә туган Сафия гаиләдә ин олы бала була, кечерәкләре – сенеле белән энесе. Боек Ватан сугышынын беренче коннәрендә ук әтисе Арифны сугышка алалар һәм Мәскәvдә барган каты бәрелеш вакытында вафат була. Кара кайгы Сафиянен йорәгендә фашистларга нәфрәтне арттырып жибәрә. Сугыштан похоронкалар авылдашларынын башкаларына да килә. Авылларда калган балалар белән картлар, фашистларга булган чиксез нәфрәттән, теләсә нинди авырлыкларны жинәргә әзер булалар; ач-ялангач халык арып-талып фронтка житештергән нәрсәләрне озатып баралар, жинvне якынайтырга тырышалар. Зарплатанын ни икәнлеген белми трудоденьга һәм бер уч арышка иртәнге таннан карангы тонгә кадәр эшлиләр. Сафия Ариф кызы истәлегендә: «Топ унышны жыйганнан сон, кырдагы башакларны жыя идек. Яз башын буразналарда калган черегән бәрәнгене чvпләдек. Урманнан чыбык-чабыкны  вязанкаларда, я чаначыкларда алып кайтып ой жылыттык, булган ашыбызны пешердек. Эштән бушаган арада эрләдек, бәйләдек, тукыдык, тектек. Бу хатын-кыз кул эшләрен хезмәт дип тә санамый торган иделәр. Хатын-кызлар бергә жыела идек тә электр утсыз, чыра гына ягып бәйләv энәләренә карамыйча торле әйберләр бәйләдек. Шулай, кул эшләре осталыгы анадан - кызына, кызыннан - оныгына кvчеп килде».
Боек Ватан сугышы тәмамлангач, тормыш жайлана, рәтләнә башлый. Унтугыз яшьтә Сафия Ариф кызы киявгә чыга. Матур гына гаилә булып яшәп китәләр. Тормыш иптәше Зариф Халим улы да гомере буе колхозларында хезмәт итә. Ул һәрбер эшкә жаваплы

карап башкарган; токта хезмәт иткән, фермада заведующий булган. Алар тату гына дvрт бала асраганнар.
Чуриле кызы Сафия апа Шехмаметьева авырлыкларны жинә-жинә яшәгән. Бер балалары авыру булып тугач, ул vзен аны тәрбияләvгә багышлый. Әниенен тырышуы һәм мәхәббәтенә карамастан, кызганычка каршы, бала иртә бакыйлыкка кvчә. Тату гаиләдәге югалту кайгысы кочле була, әмма алар бер-берсенә терәк булганга, сугыш вакытында тосле, ярату һәм ышаныч аларга коч бирә. Исән калган балалары - Нурия Зариф кызы, Шәриф белән Руфять Зариф уллары кvпне кvргән әниләренә һәрвакыт ярдәм итәргә, игътибарлы булырга тырышалар. Шундый тәрбия алганнар. Ватан сакчыларынын кызы һәм хатыны буларак, Сафия апа, буыннан буынга кvчкән гадәт буенча, улларын да хәрби хезмәткә әзерли. Туган ил сакчылары булып кайта ике улы. Шәриф Зарифович Советлар Союзында хәрби хезмәттә булса, Руфять Зарифович - Афганистанны vткән кеше. Бvген Сафия Ариф кызы Шехмаметьева доньяларда тынычлык булсын дип дога кыла; сугыш кына була кvрмәсен, тынычлыкта анын 11 оныгы һәм 13 оныкчыгы яшәсен, Россиябез чәчәк атсын һәм халкыбыз кайгы-хасрәтсез торсын дип сорый Алладан.
Юбилей конне Ельник халкынын Социаль яклау хезмәткәрләренен Президентыбыз В.В.Путиннын адреслы тәбрикләv хаты белән килvләре, авыл администрациясе житәкчесе П.М.Ямщиковнын котлауларын хезмәт ветераны зур шатлык белән кабул иткән. Болар барысы да анын һәм шул буын халкынын олы Жинvгә, илебезнен икътисатын торгызуга алып барган хезмәт батырлыкларын онытмаганнар дигән сvз. Шуна ул килгән кунакларын, якын кардәшләре кvк, кочаклаган, vпкән.

**Наилә Насырова**